КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2020 ел, 16 март г.Казань № б-570

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 19 март, б-468 нче боерыгы нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 3 июль, б-1165 нче; 2014 ел, 26 сентябрь, б-1920 нче; 2015 ел, 9 декабрь, б-2820 нче; 2016 ел, 19 декабрь, б-2997 нче; 2017 ел, 6 июнь, б-1202 нче; 2017 ел, 31 октябрь, б-2489 нчы; 2019 ел, 25 декабрь, б-3419 нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) төзелгән Татарстан Республикасы Хөкүмәте белән Горький тимер юлы – «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалының «Мәскәү – Казан – Екатеринбург» югары тизлекле тимер юл магистрален төзү проектын тормышка ашыруда үзара хезмәттәшлеген яраштыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан С.А.Киселевны һәм Ю.Л.Котловны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Стратегик үсеш идарәсенә караган инновацияләр һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы Диана Илдар кызы Гәрәеваны;

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесе Алексей Константинович Кирпичниковны;

«Югары тизлекле магистральләр» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – капиталь төзелеш департаменты директоры Михаил Николаевич Меркуловны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Стратегик үсеш идарәсе башлыгы Илнур Фәгыйль улы Нурмөхәммәтовны;

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты баш киңәшчесе Гөлназ Рәис кызы Фәйзетдинованы;

Геннадий Николаевич Балабановның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары тизлекле магистральләр» акционерлык җәмгыятенең Техник департаменты директоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин